**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 19 февралендәге 508 номерлы карары**

**Киров районының Яңа Квартал урамындагы**
**территорияне ызанлау проектын раслау турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, «Беренчел документларны әзерләү үзәге» акционердык җәмгыяте гаризасы буенча, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43, 45, 46 статьялары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 19 гыйнварындагы 71 номерлы «Киров районының Яңа Квартал урамындагы территорияне ызанлау проектын әзерләү турында»гы карары нигезендә, 2026 елның 27 гыйнварыннан алып 2026 елның 10 февраленә кадәр уздырылган җәмәгатьчелек белән фикер алышулар нәтиҗәләре буенча бәяләмәне исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә Киров районының Яңа Квартал урамындагы территорияне ызанлау проектын расларга;

2. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, кызыл линияләр чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (кушымта) (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

3. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, билгеләнә торган кызыл линияләр чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, әлеге карарны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга;

4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетына (Р.Г.Галәветдинов):

5.1. әлеге карарның кушымтасы нигезендә җир кишәрлеген дәүләт кадастр исәбенә кую һәм муниципаль милек хокукын теркәү өчен Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә ышанычнамәсез мөрәҗәгать итәргә;

5.2. җир кишәрлеген дәүләт кадастр исәбенә куйганнан соң, Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә адреслы номерлар бирү һәм белешмәләрне Дәүләт адреслар реестрына кертү өчен җир кишәрлегенең кадастр номеры турында мәгълүмат тапшырырга;

5.3. җир кишәрлекләреннән алга таба файдаланганда:

5.3.1. инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең куркынычсызлыгын һәм әлеге челтәрләрне файдаланучы оешмаларның анда тоткарлыксыз керүен тәэмин итәргә;

5.3.2. территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар өчен билгеләнгән чикләүләрне үтәргә;

5.3.3. Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2023 елның 1 декабрендәге 953-п номерлы әмере, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2010 елның 1 апрелендәге 183 номерлы «Истәлекле урын территориясеннән файдалану характеры, әлеге территориядән файдалануга чикләүләр һәм Казан шәһәренең истәлекле урыннары территориясендә хуҗалык эшчәнлегенә, проектлауга һәм төзүгә таләпләр турында нигезләмәне раслау хакында»гы әмере белән расланган «Казан шәһәре Кизик бистәсенең XVII-XVIII гасырлардагы мәдәни катламы» истәлекле урыны рәвешендә федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты чикләрендәге кишәрлек өлешендә таләпләрне үтәргә;

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 19 февралендәге
508 номерлы карары белән
расланды

**Киров районы Яңа Квартал урамындагы территорияне ызанлау проекты**

Киров районы Яңа Квартал урамындагы территорияне ызанлау проекты түбәндәгеләрдән тора:

I. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән ясала торган җир кишәрлеге турында белешмәләр булган нигезләмәләр.

II. Территорияне ызанлау сызымы.

III. Кызыл линияләр сызымы.

Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемге, билгеләнә торган кызыл линияләр чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган материаллар булып санала һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (ww.docskzn.ru) бастырылырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

## I. Ясала торган җир кишәрлеге турында мәгълүматлар булган нигезләмә

Ызанлау проекты Казан шәһәре Киров районы Яңа Квартал урамындагы территория өчен эшләнгән.

Территорияне ызанлау проекты гамәлдәге капиталь төзелеш объектлары астында җир кишәрлеген ясау, гомуми файдаланудагы территориянең кызыл линияләрен бетерү һәм билгеләү максатыннан әзерләнә.

Территорияне ызанлау проектында гомуми файдаланудагы территориянең кызыл линияләрен – Яңа квартал урамының бер өлешендә урам-юл челтәрен билгеләү карала.

Территорияне ызанлау проекты 16:50:090704:3 кадастр номерлы, муниципаль милектә булган җир кишәрлеген һәм дәүләт милкендәге җирләрне яңадан бүлү юлы белән җир кишәрлеге ясауны күздә тота.

Ясала торган җир кишәрлеге турында мәгълүмат таблицада күрсәтелгән.

| **Ясала торган җир кишәрлегенең мәйданы, кв.м** | **Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры** | **Ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Җир кишәрлеген ясау ысулы** |
|---|---|---|---|
| 15571 | 16:50:090704:3 | Җитештерү базасының биналарын һәм корылмаларын төзү өчен | Җир кишәрлеген һәм дәүләт милке җирләрен яңадан бүлү |

Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясындагы 3 пункты нигезендә ясала торган җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнеше һәм алардан рөхсәт ителгән файдалану дип җир кишәрлекләреннән ясалган җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнеше һәм алардан рөхсәт ителгән файдалану танылa.

Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы «Казан шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында»гы карары белән расланган Казан шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре (үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – Кагыйдәләр) нигезендә ясала торган җир кишәрлеге катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш территориаль зонасында урнашкан.

Кагыйдәләрнең 30 статьясы буенча, рөхсәт ителгән файдалану төре җитештерү базасы бина һәм корылмалары булган ясала торган җир кишәрлегенең иң чик максималь һәм минималь зурлыклары билгеләнмәгән.

Алга таба ясала торган җир кишәрлеге милекчесенә рөхсәт ителгән файдалану төрен Кагыйдәләрдә билгеләнгән шәһәр төзелеше регламентларына туры китерергә тәкъдим ителә.


Ясала торган җир кишәрлеге тиеш:

- җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, яңа инженерлык коммуникацияләре салу өчен башка трасса сайлау кирәк булганда һәм мөмкин булмаганда, тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

- гамәлдәге инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, эксплуатацияләүче оешмаларның тоткарлыксыз керү мөмкинлеген;


- Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2023 елның 1 декабрендәге 953-п номерлы әмере, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2010 елның 1 апрелендәге 183 номерлы «Истәлекле урын территориясеннән файдалану характеры, әлеге территориядән файдалануга чикләүләр һәм Казан шәһәренең истәлекле урыннары территориясендә хуҗалык эшчәнлегенә, проектлауга һәм төзүгә таләпләр турында нигезләмәне раслау хакында»гы әмере белән расланган истәлекле урын рәвешендәге федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты чикләрендәге кишәрлекнең бер өлешенә таләпләрне үтәргә.

# II. Территорияне ызанлау сызымы




| **Шартлы билгеләр:** | |
|---|---|
| | ызанлау проекты әзерләнә торган территориянең чиге |
| | ясала торган җир кишәрлеге чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлегенең чиге |
| | кадастр кварталының чиге |
| ○ 1 | ызанлау проекты расланган территория чигенең характерлы ноктасы |
| ● н1 | ясала торган җир кишәрлегенең характерлы ноктасы |
| 16:50:090704 | кадастр кварталы |
| 16:50:090704:3 | җир кишәрлегенең кадастр номеры |

# III. Кызыл линияләр сызымы




| **Шартлы билгеләр:** | |
|---|---|
| | ызанлау проекты әзерләнә торган территориянең чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлегенең чиге |
| | кадастр кварталының чиге |
| | гамәлдәге кызыл линияләр |
| | билгеләнә торган кызыл линияләр |
| | гамәлдән чыгарыла торган кызыл линияләр |
| ● к1 | билгеләнә торган кызыл линиянең характерлы ноктасы |
| 16:50:090704 | кадастр кварталы |
| 16:50:090704:3 | җир кишәрлегенең кадастр номеры |